# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

"Яшьләр турында"

Әлеге Закон, Татарстан Республикасының яшь гражданнары мәнфәгатьләреннән һәм бөтен халыкның мәнфәгатьләреннән чыгып:

республикада дәүләтнең яшьләр сәясәте принципларын раслый;

аны гамәлгә ашыруның икътисадый, хокукый, иҗтимагый һәм оештыру шартларын һәм гарантияләрен билгели;

халыкның башка иҗтимагый һәм җәмгыяви төркемнәре белән бергәттән балаларның һәм яшьләрнең[*] җәмгыяви мөмкинлекләрен тигезләүче гамәлләрне тәэмин итүгә юнәлдерелгән оештыру - хокукый чаралар системасын беркетә;

шәхеснең ирекле үсеше өчен гамәли шартлар һәм кызыксындыру чараларын тудыруны, яшь гражданнарның тормыш максатларын гамәлгә ашыруны, аларның җәмгыяви-икътисадый һәм сәяси эшчәнлектә актив катнашуын тәэмин итәргә омтыла.

Закон яшьләр органнары, балаларның һәм яшьләрнең иҗтимагый берләшмәләре[**] белән республиканың яшь гражданнары арасындагы мөнәсәбәтләрне җайга сала.

-------------

* алга таба: яшь гражданнар

** алга таба:яшьләр оешмалары

Законның кече 30 яшькә кадәрге яшь гражданнарга /яшьләргә/, шулай ук аларның Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче ата-аналарына, балаларны һәм яшьләрне тәрбияләүче затларга кагыла.

Закон яшьләр сәясәтенең өстенлек принцибын җәмгыять тәрәккыятенең иң мөһим шарты итеп билгели.

I бүлек. Төшенчәләрне билгеләү

I статья. Әлеге Законда яшь граждан /яшь кеше/ дип түбәндәгеләр санала:

бала дип, әгәр ул I4 яшькә җитмәгән булса һәм гамәлдәге законнарда башкасы каралмаган булса;

яшүсмер дип, әгәр аңа I4 яшьтән алып I8 яшькә кадәр булса;

балигъ булмаган дип, әгәр ул I8 яшькә җитмәгән булса.

2 статья. Әгәр гаиләдә ир белән хатынның берәрсе 30 яшькә җитмәгән булса, өйләнешүдән соңгы беренче өч елда /бала туган очракта – өйләнешү чорына карамастан/ бу гаилә Законда яшь гаилә санала, ә балалы һәм тулы булмаган гаиләләрдә анасы яки атасы 30 яшькә җитмәгән булса, бу гаилә Законда яшь гаилә санала.

2 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

3 статья. Дәүләтнең яшьләр сәясәте

I. Дәүләтнең яшьләр сәясәте – Татарстан Республикасының хакимият һәм идарә органнары тарафыннан гамәлгә ашырылучы һәм Татарстан Республикасы эшчәнлегенең яшь гражданнарның җәмгыяви яктан аякка басуы һәм үсеше өчен, бөтен халык мәнфәгатьләрендә үзләрен тулысынча күрсәтә алсыннар өчен, икътисадый, җәмгыяви, мәдәни, оештыру һәм хокукый шартлар һәм гарантияләр тудыруны үзенең максаты итеп куйган төп юнәлешләреннән берсе.

2. Татарстан Республикасында дәүләтнең яшьләр сәясәте түбәндәге үзенчәлекләргә нигезләнеп төзелә:

яшь гражданның шәхси суверенлыгын, җәмгыяви статусын тану һәм үтәү, шәхес хокукларының дәүләт мәнфәгатьләренә караганда өстенрәк булуы;

яшь кешенең шәхси һәм җәмгыяви үсешендә ярдәм алуга хокукын, шәхси тәҗрибәсе булуга хокукын, инициативага хокукын тану; үз көченә ышаныч тәрбияләү;

җәмгыятькә тулысынча, аеруча балаларга һәм яшүсмерләргә кагылышлы сәясәт һәм программалар әзерләүдә һәм аларны гамәлгә ашыруда яшь гражданнарның турыдан-туры катнашуы; яшьләргә, аларның эшчәнлегенә һәм җәмгыять алдындагы җаваплылыгына тулы сәяси ышаныч;

җәмгыяви гаделлекне һәм законнарны ихтирам итү;

яшь гражданның милли абруен ихтирам итү һәм яшь гражданның башкаларның милли абруен ихтирам итүе, яшьләрнең барлык категорияләрендә милләтара аралашу мәдәниятен тәрбияләү;

өлкәннәргә карата ихтирам, кайгыртучанлык һәм шәфкатьлелек тәрбияләү; буыннар күчешен саклау;

яшь гражданнарның хокукый һәм җәмгыяви якланышын тәэмин итү;

күләме, төрләре һәм сыйфаты ягыннан яшь гражданның шәхес буларак күпкырлы үсешенә, мөстәкыйль гамәли эшчәнлеккә әзерлегенә һәм аңа керешүенә ярдәм итәрлек белем алуы өчен, тәрбияви, рухи, психологик һәм физик үсеше өчен, һөнәргә өйрәнүе һәм эш белән тәэмин ителүе өчен кирәкле җәмгыяви шартлар тудыру; аеруча яшь кешеләрнең мәктәптән /югары уку йортыннан/ соң

белгеч булып киту чорында;

һәр яшь кешегә үз тормышын үзе җайга салырлык уңай шартлар тудыру яисә аларны саклау;

балаларның һәм яшьләрнең җәмгыяви, рухи һәм физик үсеше өлкәсендә инициативалы җәмәгать эшчәнлегенә, хезмәткә карата битарафлыкны җиңеп чыгуына ярдәм итү; конкрет эшләр аркылы яшьләрне җәмгыятебезнең үсеш программаларына җәлеп итү;

әлеге Законда яшь граждан өчен билгеләнгән төп гарантияләрнең республикадагы җәмгыяви-икътисадый үсеш дәрәҗәсенә туры килүен тәэмин итү;

балаларның һәм яшьләрнең хокукларын яклау өлкәсендәге халыкара хокукый актларны үтәү;

яшь гражданның үз хокукларын һәм бурычларын белеп, шулар нигезендә эш итүләрен дә кертеп, хокуклары һәм бурычлары хакында хәбәрдар булулары; шәхес турындагы мәгълүматларны яклау;

4 статья. Дәүләтнең яшьләр сәясәте өлкәсендә Татарстан Республикасының вәкаләтләре

Татарстан Республикасының югары хакимият һәм идарә органнары карамагына түбәндәгеләр керә:

республикадагы дәүләтнең яшьләр сәясәтен әзерләү һәм гамәлгә ашыру;

дәүләтнең яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыручы барлык оешмаларның хокукый статусын билгеләү һәм эшчәнлекләрен җайга салу; аларның балалар һәм яшьләр белән үзара мөнәсәбәтләрен көйләү;

балаларның һәм яшьләрнең үсешен билгеләүче, балаларга, яшьләргә һәм гаиләләргә күрсәтелүче җәмгыяви ярдәмнең һәм хезмәт күрсәтүләрнең минималь дәрәҗәсен һәм әлеге Закон, башка норматив актлар нигезендә аларның хокуклары һәм ирекләре га-

рантияләрен беркетүче дәүләтнең җәмгыяви нормаларын һәм нормативларын урнаштыру;

балалар һәм яшьләр мәнфәгатьләре буенча дәүләт хезмәтенең эшчәнлеген оештыру һәм җайга салу;

әлеге Законны гамәлгә ашыру буенча дәүләтнең яшьләр сәясәтенә кагылышлы республиканың максатчыл һәм күпкырлы программаларын /гамәлләрен/ раслау һәм аларның үтәлешен оештыру, аларның үтәлеше һәм тәэмин ителеше турындагы мәсьәләләрне хәл итү;

республикада дәүләтнең яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән бюджет һәм бюджеттан тыш финанс чараларын булдыру һәм файдалану тәртибен, шулай ук, хакимиятнең җирле органнары белән килешеп, әлеге максатлар өчен алар тарафыннан ирекле рәвештә кертелүче акчаларны куллану тәртибен билгеләү;

дәүләтнең яшьләр сәясәте мәсьәләләре буенча халыкара һәм республикаара элемтәләрне гамәлгә ашыру;

балалар һәм яшьләр мәсьәләләре буенча статистика алып бару;

балаларга һәм яшьләргә карата Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән вазыйфаларны хокукый мөнәсәбәтләрнең һәр субъекты /дәүләт органнары, урындагы затлар һәм гражданнар, шулай ук җәмәгать оешмалары/ тарафыннан үтәлешен тикшереп тору;

әлеге Закон һәм башка норматив актлар нигезендә республикада дәүләтнең яшьләр сәясәтен оештыруның һәм гамәлгә ашыруның башка мәсьәләләре.

<u>5 статья.</u> Яшьләр сәясәте өлкәсендә җирле органнарның вәкаләтләре

I. Хакимиятнең һәм идарәнең җирле органнары карамагына түбәндәгеләр керә:

әлеге Закон нигезендә җирле һәм төбәк программаларын әзерләү һәм үзләре карамагындагы территориядә әлеге Закон нигезендә дәүләтнең, җирле территориянең һәм төбәкнең яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру;

балалар һәм яшьләр мәнфәгатьләре буенча органнар төзү;

җәмгыяви өстәмә нормалар һәм нормативлар билгеләү;

балаларның һәм яшьләрнең яңалык алып килүче программаларын балаларның һәм яшьләрнең җәмәгать фондлары яисә идарәнең җирле органнары аша бюджеттан тыш финанслау;

әлеге Законның 4 статьясы тарафыннан республика карамагына тапшырылган мәсьәләләрдән тыш, яшьләр сәясәтенең әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив актлары нигезендә күрсәтелгән башка мәсьәләләре.

2. Хакимиятнең һәм идарәнең җирле органнары балалар һәм яшьләр мәнфәгатьләре буенча җирле органнарның дәүләт, җәмәгать, хуҗалык һәм башка органнары белән мөнәсәбәтләренең тәртибен билгели.

6 статья. Татарстан Республикасында дәүләтнең яшьләр сәясәте турындагы законнар

1. Дәүләтнең яшьләр сәясәте турында Татарстан Республикасы законнары Татарстан Республикасы Конституциясенә нигезләнә һәм әлеге Законнан, балаларга һәм яшьләргә кагылышлы мәсьәләләрне җайга салучы башка законнардан гыйбарәт.

2. Республиканың җәмгыяви-икътисадый үсешенә карап, яшь гражданнарның хокукларын һәм бурычларын гамәлгә ашыру буенча гарантияләрне киңәйтү һәм ныгыту йөзеннән, аларның хокукларын һәм бурычларын җайга салучы законнарны даими рәвештә яңартып торуны республика тәэмин итә.

3. Әгәр республиканың халыкара һәм республикаара шартнамәсендә, әлеге Законда яисә Татарстан Республикасының дәүләтнең яшьләр сәясәте турындагы башка закон актларындагыга караганда, бүтән кагыйдәләр билгеләнгән булса, ул вакытта халыкара һәм республикаара шартнамә кагыйдәләре кулланыла.

## 3 бүлек. Яшь гражданнарның хокукый һәм җәмгыяви яклнышы һәм җаваплылыгы

7 статья. Яшь гражданнарны хокукый һәм җәмгыяви яклауның гарантияләре

I. Татарстан Республикасы үз территориясендә яшь гражданнарның, яшенә, җенесенә, теленә, милләтенә, дини инануларына, сәяси мәсләгенә, нинди фиркадә әгъза булуына, мөлкәти, җәмгыяви һәм башка халәтенә, никах нигезендә яисә никахтан башка туууына һәм бүтән сәбәпләргә карамастан, табигый, читләштерелми торган хокукларын һәм ирекләрен саклауны гарантияли.

2. Яшь гражданнар Татарстан Республикасының Конституциясендә һәм башка закон актларында гражданнар өчен каралган җәмгыяви-икътисадый, сәяси һәм шәхси хокукларга һәм ирекләргә тулысынча ия булалар.

Законда күрсәтелгәннән тыш, яшенә бәйле рәвештә яшь гражданнарның нинди дә булса хокукларын һәм ирекләрен турыдан-туры яисә читләтеп чикләүгә юл куелмый.

3.3.I. Яшь гражданнар дәүләт оешмалары һәм дәүләтнеке булмаган оешмалар аларга кагылышлы карарлар кабул иткәндә катнашалар.

Алар дәүләт органнарыннан үзләренең хокукларын аңлатучы мәгълүматларны тиешле тәртиптә алырга хаклы.

3.2. һәр бала, яшүсмер һәм яшь кеше, үзенең яшенә карап,

үсеш, тәрбия, үз хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау мәсьәләләре белән балалар һәм яшьләр мәнфәгатьләре буенча органнарга, дәүләтнеке һәм дәүләтнеке булмаган учреждениеләргә һәм оешмаларга мөрәҗәгать итәргә һәм шушы хакта теләкләрен белдерергә хаклы.

3.3. Яшь гражданнар консультацияләр алырга хаклы, әгәр бу консультацияләр каршылыклы яисә бик кыен очраклар аркасында кирәк икән һәм әгәр тәрбиясендә яшь граждан яисә балалар булган затлар әлеге консультацияләргә комачаулысалар, консультацияләр, аларның тәрбиясе белән шөгыльләнүчеләргә хәбәр ителмичә генә, шул исәптән аноним рәвештә дә үткәрелергә мөмкин.

4.4.1. Дәүләт яшь шәхеснең бердәнберлеген таный, ә ул шәхеснең ирекге бары тик закон нигезендә генә чикләнергә мөмкин.

4.2. Һәр яшь кеше, үзаңына карап, нинди милләттән булуын билгеләргә хаклы.

Беркем дә үзенең милләтен билгеләгәндә һәм күрсәткәндә мәҗбүр ителергә тиеш түгел.

4.3. Беркем дә рәхимсез һәм кешелек абруен кимсетерлек мөгамәләгә дучар ителергә тиеш түгел, шулай ук, законда каралган очраклардан тыш, җәзага тартылырга, үзенең ризалыгыннан, ата-аналары яисә аларны алмаштыручы затлар ризалыгыннан башка табибләргә күрсәтелергә һәм фәнни тәҗрибәләргә дучар ителергә тиеш түгел.

4.4. Балаларны һәм яшүсмерләрне урлау, берәр максат өчен тоткын итеп алу, балалар белән сәүдә итү гаять рәхимсез җинаять дип санала.

5. Балаларны сәяси көрәшкә җәлеп итү һәм баланың нинди дә булса сәяси оешмаларда һәм фиркаләрдә катнашуы тыела.

6.6.1. Дәүләт шәхес турындагы мәгълүматны /белешмәне/ тиешле рәвештә, законда каралган тәртиптә җыйган, саклаган һәм

кулланган вакытта аның хәбәр ителмәвен гарантияли.

6.2. Дәүләт органнары тарафыннан үзенә карата мәгълүмат җыелган зат,әгәр ул мәгълүмат башка затларның мәнфәгатьләренә кагылмаса, шушы мәгълүматны соратып алырга хаклы.

6.3. Әгәр санап үтеләчәк чаралар җинаять җәзасы яисә административ җаваплылыкка тарту рәтенә кертелмәсә яисә хөкем карары нигезендә тәрбия рәвешендәге мәҗбүри чаралардан саналмаса, республикадагы дәүләт органнары һәм урындагы затлар, педагогик һәм җәмгыяви хезмәткәрләр тарафыннан балигъ булмаганнарга карата җинаять билгесе сыйфатындагы алар кылган гамәлләр һәм хокук бозулар хакындагы белешмәләрне халыкка таратуга нигезләнгән тәэсир итү чаралары күрелмәскә тиеш.

7. Татарстан Республикасы уңайлыкларга ия булуда һәм аларның шәхес керткән өлеш белән тормыш дәрәҗәсенә туры килүен тәэмин итүдә тигез мөмкинлекләр тудыра.

8 статья. Балигъ булмаганнарны яклау

I. I8 яше тулмаган затлар /балигъ булмаганнар/ дәүләтнең махсус яклавыннан файдаланалар.

2. Дәүләт балигъ булмаганнарның әхлагын көч куллану культы һәм порнография таратудан, җинаять эшчәнлегенә җәлеп ителүдән, эчкечелеккә, фахишәлеккә, наркоманиягә һәм токсикоманиягә җәлеп ителүдән хокукый, педагогик һәм психологик яклауны тәэмин итә.

3.3.I, Дәүләт, балигъ булмаганнарның яшь үзенчәлекләре аркасында кылган гамәлләренең асылына төшенеп җитмәүләрен исәпкә алып, кылган гамәлләре нигезендә хокукка ия булуларын, үзләре өчен вазыйфалар булдыруларын һәм хокукый җаваплылык

сәләтләрен чикли, шулай ук хокукларын гамәлгә ашыруның аерым тәртибен билгели.

3.2. Яшь гражданнарның хокукка сәләтен һәм гомуми сәләтен чикләү, шулай ук аларның хокукларын гамәлгә ашыруның махсус тәртибе бары тик закон тарафыннан гына һәм һичшиксез яшь гражданнарның мәнфәгатьләренә карап кына билгеләнергә мөмкин.

3.3. Законда каралган тәрбияви мәҗбүри чаралар балигъ булмаганнарга карата бары тик хөкем карары нигезендә генә кулланыла.

4. Дәүләт балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау максатларында хокук саклау органнары һәм гадел хөкем органнары составында тиешле төзелмә бүлекчәләр оештыра, шулай ук сорашып белү һәм хөкем тикшерүе барышына, гадел хөкем эшчәнлегенә һәм хөкем составына, җәза чорын үтү шартларына махсус таләпләр билгели.

9 статья. Ата-аналарның балаларны карау һәм тәрбияләү өлкәсендәге хокуклары һәм бурычлары

I. Балаларны карау һәм тәрбияләү - ата-аналарның табигый хокукы һәм бурычы. Дәүләт бу бурычны гамәлгә ашыруны күзәтә.

2.2.I. Ата-аналар, аларны алмаштыручы затлар, үзләренең сәләтләреннән һәм матди мөмкинлекләреннән чыгып, баланы карау, тәрбияләү, сәламәтлеген саклау, аның мөстәкыйль тормышка әзерләнүе өчен тиешле шартлар тәэмин итәләр һәм,закон нигезендә, керемнәренең күләменә бәйле рәвештә баланы балалар учреждениеләрендә карау һәм тәрбияләү өчен кирәкле чыгымнарны түлиләр.

2.2. Ата-аналар үзләренең балигъ булмаган балаларын тиешенчә карамаган, үстермәгән һәм тәрбияләмәгән өчен һәм аларның

иҗтимагый тәртибе өчен, шулай ук үз балаларының әлеге Законда һәм башка норматив актларда каралган хокукларын һәм ирекләрен бозган өчен тигез дәрәҗәдә җаваплы булалар.

3.3.I. Балаларын карау һәм тәрбияләү өчен уңайлы шартлар тудыру максатларында яшь гражданнар һәм яшь гаиләләр хосусый торак төзелеше һәм яшьләрнең торак комплекслары өчен җир кишәрлекләре бирелгәндә ташламалар алырга, шулай ук түбәндәгеләр өчен озак вакытка бирелүче кредитлар алырга хаклы:

торак йортлар һәм фатирлар, җәмгыяви-мәдәни-көнкүреш максатларында кулланылучы объектлар сатып алу һәм төзү;

торак-төзелеш кооперативларына, яшелчәчелек һәм бакчачылык ширкәтләренә һәм җәмгыятьләренә керү кертемнәрен түләү;

йорт-җир хуҗалыгы булдыру, озак вакытлар кулланыла торган йорт кирәк-яракларын сатып алу;

дәүләтнеке булмаган уку йортларында укыган өчен түләү;

балаларны карау һәм тәрбияләү белән бәйле башка максатлар.

3.2. Алда күрсәтелгән куллану кредитлары шул максатлар өчен бирелгән үзәкләштерелгән кредит ресурслары чикләрендә түбән процентлар бәрабәренә банклар һәм фондлар тарафыннан бирелә һәм балалар һәм яшьләр мәнфәгатьләре буенча дәүләт комитеты тәкъдиме буенча ел саен бюджет төзегән вакытта Татарстан Республикасы Хөкүмәте билгеләгән ташламалы тәртиптә түләнәләр.

4. Дәүләт яшьләр торак төзелешен хуплый, моның өчен матди һәм хокукый шартлар тудыра, яшь гражданнарга дәүләт һәм коммуналь торак фондыннан торак алырга ярдәм итә.

<u>10 статья.</u> Балаларны тәрбияләгәндә гаиләләргә дәүләт ярдәме

I. Дәүләт балалары булган гаиләләргә финанс һәм матди ярдәм күрсәтә.

2. Балалары туганда яшь гаиләләргә законнар нигезендә билгеләнгән тәртиптә озак вакытка ташламалар бирелергә мөмкин.

3. Балалары булган гаиләләр балаларын карау һәм тәрбияләү өчен пособиеләр һәм компенсацияләр алу хокукыннан файдаланалар.

Пособиеләрнең һәм компенсацияләрнең күләмнәре һәм түләү шартлары законнар нигезендә билгеләнә.

II статья. Балалар учреждениеләрендә балаларны тәрбияләүдә ярдәм итү

I.I.I. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләрендә, балалар йортларында балаларны тиешенчә карау, тәрбияләү һәм укыту гарантияләнергә тиеш.

I.2. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләре балаларны карау һәм тәрбияләү эшләренә ата-аналарны да җәлеп итәләр.

2.2.I. Ятим балаларга, шулай ук тәрбиягә авыр бирелүчән балаларга һәм яшүсмерләргә гаилә тәрбиясен төрле рәвештә алсыннар өчен шартлар тудырыла.

2.2. Баланы яисә яшүсмерне үз гаиләсеннән тыш карауны һәм тәрбияләүне үзенә алырга теләүче затның, законда билгеләнгән очраклардан гайре, рөхсәт кәгазе булырга тиеш.

2.3. Халык депутатларының җирле Советлары, балалар һәм яшьләр мәнфәгатьләре буенча органнар түбәндәгеләрне тәэмин итәләр:

вакыты җитеп балалар йортларыннан киткән ятимнәрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауны;

аларга тиешле һәм җитәрлек күләмдә акчалата-әйберләтә пособиеләр бирүне;

дәүләт иминлеген /страхованиесен/;

үз тораклары булмаганнарга чираттан тыш торак бирүне;

эшкә урнаштыруны һәм аларга уңайлыклар тудыруны.

3. Хакимиятнең һәм идарәнең республика һәм җирле органнары

аз керемле мохтаҗ гаиләләрдәге балаларга һәм яшь гражданнарга түбәндәге чыгымнарны компенсацияләү рәвешендә җәмгыяви яклау чаралары билгеләнә:

баланы мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләрендә тоткан һәм тәрбияләгән өчен;

балалар киемнәре, мәктәп һәм спорт киемнәре, аяк киемнәре, дәреслекләр һәм башка уку әсбаплары сатып алу өчен, яшьләргә кирәкле товарлар сатып алу өчен;

укучыларны ашханәләрдә ашату өчен;

укучыларга башка пособиеләр бирү өчен;

класстан тыш учреждениеләрдә балаларны укытуга түләү өчен;

укучыларның, яшь гражданнарның һәм аларның гаиләләренең башка ихтыяҗлары өчен.

Моның өчен законда билгеләнгән тәртиптә салымнарның махсус төрләре кертелергә мөмкин.

4. Әлеге статьяда каралган хезмәтләрне күрсәтү тәртибе һәм аларның күләмнәре, аларны гамәлгә ашыру һәм тиешенчә үстерү әлеге Закон, гамәлдәге законнар һәм җирле Советларның карарлары нигезендә билгеләнә.

I2 статья. Яшь гражданнарның бурычлары

I. Яшь гражданнар Татарстан Республикасы Конституциясендә, әлеге Законда һәм башка законнарда гражданнар өчен каралган вазыйфаларны башкаралар.

2. Балалар һәм яшь гражданнар законнарны һәм гаиләдә, җәмгыятьтә үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен үтәргә тиешләр;

үзләренең сәләтләрен ачыкларга, белем алырга, үзләрен мөстәкыйль тормышка,хезмәт эшчәнлегенә һәм уңайлыкларга үз хезмәте нәтиҗәсендә ирешүгә әзерләргә;

ата-аналарны ихтирам итәргә, башка гражданнарның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен, үз милләтенең һәм башка милләтләрнең мәдәни гореф-гадәтләрен хөрмәт итәргә; тирә-як мохиткә сакчыл карарга;

ата-аналар, олы яшьтәгеләр, авырулар һәм үз гаиләсендәге ярдәмгә мохтаҗлар турында кайгыртырга һәм аларга ярдәм күрсәтергә.

3. Яшь гражданнарга, башка гражданнар өчен билгеләнгән вазыйфалардан тыш, нинди дә булса бүтән төрле өстәмә вазыйфалар, шул исәптән дәүләт тәртибен һәм иҗтимагый тәртипне саклау буенча да йөкләү рөхсәт ителми, законнарда мондый вазыйфалар махсус каралган очракларда гына алар рөхсәт ителергә мөмкин.

<u>I3 статья.</u> Яшь гражданнарның гарантияләнгән җәмгыяви яклауга хокуклары

I. Яшь гражданнар, расасына,җенесенә, дини инануларына, милләтенә һәм җәмгыяви халәтенә, керемнәренең дәрәҗәсенә, башка сәбәпләргә карамастан, әлеге Законның 3 статьясындагы 2 өлеше нигезендә җәмгыяви яклауларның гарантияләнгән тиешле минимумын алырга хаклылар.

2. Яшь гражданнарга җәмгыяви хезмәт күрсәтелүләрнең гарантияләнгән дәрәҗәсен беркетүче җәмгыяви нормалар һәм нормативлар системасын әлеге Закон һәм башка норматив актлар нигезендә дәүләт билгели.

3. Хезмәт күрсәтелүләргә /ярдәмгә/ хокукы булган яшь гражданнар хезмәт күрсәтүче учреждениеләрне, дәүләтнеке һәм дәүләтнеке булмаган оешмалар һәм учреждениеләр күрсәтүче хезмәт

төрләрен ирекле рәвештә сайлый алалар.

Хезмәт /ярдәм/ күрсәткәндә учреждениеләр һәм оешмалар түбәндәгеләрне исәпкә алалар:

ата-аналарның, тәрбиячеләрнең яисә тәрбиягә алучыларның тәрбия юнәлешләрен, шулай ук дини тәрбияне ачыклаганда, ата-аналарның, тәрбиячеләрнең яисә тәрбиягә алучыларның һәм яшь гражданнарның хокукларын;

баланың һәм яшь кешенең мөстәкыйль һәм нигезле гамәлләр кылуга омтылучы ихтыяҗларын һәм мөмкинлекләрен, шулай ук яшьләрнең һәм аларның гаиләләренең махсус җәмгыяви һәм мәдәни ихтыяҗларын һәм үзенчәлекләрен;

кызларның һәм ир-балаларның аерымлыкларын һәм шушы нигездә аларның тигез хокуклылыгын тәэмин итүне.

4.4.I. Дәүләт мәктәп укучыларына, башка төрле уку йортларының укучыларына һәм студентларына, интернационалист хәрбиләргә, вакытлы гамәли хәрби хезмәт үтүче хәрбиләргә мәдәни-агарту, физик тәрбия-спорт һәм сәламәтләндерү учреждениеләреннән файдаланганда ташламалы яисә түләүсез режим тәэмин итә.

4.2. Хакимиятнең һәм идарәнең республика һәм җирле органнары укучы һәм эшләүче яшьләр арасында спорт туризмын һәм үзешчән туризмны, көрәшнең милли төрләрен, спорт һәм физик тәрбиянең башка төрләрен үстерүгә акча бүлеп бирүне карыйлар, шулай ук моның өчен тиешле шартлар тудыралар.

4.3. Хакимиятнең һәм идарәнең республика һәм җирле органнары әлеге статьяның 4.I. пунктында күрсәтелгән яшь гражданнарга түбәндәгеләр өчен түләгәндә ташламалар билгеләргә мөмкин:

тукланү өчен;

коммуналь-көнкүреш хезмәте өчен;

көнкүрешкә, транспортка һәм башка тармакларга һәм предприятиеләргә тиешле бюджетлардан компенсация бирүне күздә тотып, тимер юл, һава юлы, су юлы транспортында, автомобиль транспортында һәм шәһәр транспортының башка төрләрендә йөрүгә. Ташламалы режим шулай ук яшьләр туризмы һәм хезмәттәшлек тәртибендә, шул исәптән балаларның һәм яшьләрнең халыкара туризмы, студентларның, укучыларның һәм яшьләрнең халыкара фикер һәм тәҗрибә алмашулары тәртибендә пассажирларны йөртү өчен транспорттан файдалануга да кагылырга мөмкин. Алда күрсәтелгән ташламалар календарь елының теләсә кайсы вакытында бирелә ала.

4.4. Укучыларга, студентларга һәм аспирантларга бирелүче стипендияләр һәм компенсацияләр хезмәт хакының минималь күләменнән чыгып исәпләнелгән күләмнәрдә һәм минималь куллану бюджетының зурлыгын исәпкә алган күләмнәрдә билгеләнә.

4.5. Югары һәм махсус урта уку йортларында җитештерүдән аерылып укучы балалы яшь хатыннар стипендияне тулысынча алырга хаклы, бала караган өчен өлешчә түләнә торган ял вакытында бирелүче пособиене алырга хаклы.

5. Табышларының /керемнәренең/ 50 проценттан артыгракгы балаларның һәм яшьләрнең билгеләнгән тәртиптә расланучы программаларына тотыла /җибәрелә/ торган мәдәният, мәгариф учреждениеләре, яшьләрнең торак комплекслары табышка /керемгә/ салымнан азат ителәләр.

6. Дәүләт һәм җәмәгать органнарының һәм урындагы затларның яшь гражданнарга күрсәтелә торган җәмгыяви хезмәтләрнең күләмен, шулай ук аларның сыйфатын гарантияләнгән дәрәҗәдән

кимүгә китерүче карарлар кабул итәргә һәм башка шундый гамәлләр кылырга хаклары юк.

7. Яшь гражданнарның әлеге статьяда каралган хокуклары дәүләт тарафыннан гарантияләнә, ә хокуклары бозылган очракта гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә яклана.

8. Дәүләт һәм җәмәгать органнарының, урындагы затларның хокукка каршы гамәлләренә һәм карарларына карата гамәлдәге законнар нигезендә хөкемгә шикаять белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Шикаять хокукы бозылган граждан һәм аның вәкиле тарафыннан, шулай ук яшьләр оешмасы вәкиле яисә балалар һәм яшьләр мәнфәгатьләре буенча дәүләт хезмәте органы тарафыннан бирелә ала.

<u>I4 статья.</u> Оешмаларны һәм гражданнарны балаларга һәм яшьләргә җәмгыяви ярдәм күрсәтүгә җәлеп итү

I. Милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләрне, оешмаларны, учреждениеләрне һәм кайбер гражданнарны балаларга һәм яшьләргә җәмгыяви ярдәм күрсәтү, балалар һәм яшьләр өчен, спорт өчен товарлар җитештерү, нәниләр өчен югары сыйфатлы ризык әзерләү, арзан бәяле хезмәт күрсәтү эшчәнлегенә җәлеп итү шартнамә нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Алда күрсәтелгән оешмалар яисә затлар - бер яктан, балалар һәм яшьләр мәнфәгатьләре буенча дәүләт хезмәте органнары - икенче яктан үзара төзелгән шартнамәләрендә түбәндәгеләрне билгелиләр:

әлеге оешмалар яисә затлар тарафыннан күрсәтелүче хезмәтнең төрләре һәм асылы;

дәүләт хезмәтенең аларга акчалата яисә башкача матди ярдәм күрсәтүе шартлары;

күрсәтелүче хезмәтнең сыйфатына карата таләпләр.

3. Предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар, яшь гражданнарның һәм яшь гаиләләрнең эшчәнлекләре барышында керткән өлешләренә карап, аларга үзләре белән яшь граждан арасында төзелгән шәхси шартнамәдә билгеләнгән тәртиптә үз акчалары исәбеннән 9,10 статьяларда күрсәтелгән ссудаларны бирә һәм ташламалы тәртиптә каплый алалар.

4. Дәүләт яшь гражданнарны җәмгыяви яктан аякка бастыру һәм үстерү өчен, аларның иҗади мөмкинлекләреннән файдалану өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән программаларны гамәлгә ашыруны һәм предприятиеләрнең, оешмаларның кертемнәрен /инвестицияләрен/ файдалануны хуплый.

15 статья. Яшь гражданнарның мәгариф өлкәсендәге хокукларын тәэмин итү

1. Дәүләт балалар һәм яшьләр арасында мәгарифнең дәрәҗәсен күтәрүгә ярдәм итә.

2. Укучыларның һәм студентларның укыту һәм укыту-тәрбия учреждениеләре /һәм аларның тулай тораклары/ хакимияте белән бәйле хокуклары һәм бурычлары түбәндәгеләр нигезендә билгеләнә:

"Мәгариф турында" Татарстан Республикасы Законы һәм башка закон актлары;

укыту- укыту-тәрбия учреждениеләренең тулай торакларның үзидарә органнары карарлары нигезендә, бу карарларны кабул итүдә студентлар, укучылар яисә аларның законлы вәкилләре катнашырга тиеш;

укучылар, аларның коллективлары белән укыту, укыту- тәрбия учреждениеләре /тулай тораклары арасында төзелгән шартнамәләр /килешүләр/.

3.3.1. Яшь гражданнар белән укыту, укыту-тәрбия учреждениеләре арасындагы хокук мөнәсәбәтләре әлеге мөнәсәбәтләрдә катнашучыларның тигез хокуклылыгына нигезләнә.

3.2. Хакимиятнең һәм идарәнең республика һәм җирле органнары укучылар һәм студентлар проблемаларының бер өлешен хәл итүне үз өстенә алырга әзер булган укучылар һәм студентлар төзелмәләре өчен аеруча уңайлы режим тудыра һәм эшчәнлекләренә ярдәм күрсәтә.

4. Мәктәп укучыларын, укучыларны, гражданлык мәгариф учреждениеләрендәге көндезге бүлекләрнең студентларын үз ризалыкларыннан башка яисә ата-аналары /аларны алмаштыручы затлар/ рөхсәтеннән башка укыту программаларында каралмаган хезмәткә җәлеп итү тыела.

Укыту-тәрбия учреждениеләренең хакимияте һәм хезмәткәрләре укучыны үзенең хокукларыннан ваз кичәргә мәҗбүр итәргә хаклы түгел.

5. Дәүләт студентларның хокукый халәтен бердәйләштерү, дипломнарын үзара тану, укуларын чит илләрдә дәвам итү гарантияләре мәсьәләләрен хәл итә.

16 статья. Талантлы яшьләргә дәүләт ярдәме

1. Җәмгыятьнең акыл һәм иҗади мөмкинлекләрен саклау һәм үстерү максатында дәүләт талантлы яшь гражданнарны ачыклау өчен кирәкле шартлар тудыра, махсус премияләр, стипендияләр һәм пособиеләр булдырып, аларга махсус ярдәм күрсәтә.

2. Аеруча сәләтле яшь гражданнар укырга, стажировкага һәм белемен күтәрү өчен чит дәүләтләрнең уку йортларына конкурс нигезендә җибәрелергә мөмкин.

17 статья. Яшь гражданнарның мәдәният өлкәсендәге хокукларын тәэмин итү

I. Дәүләт Татарстан Республикасының мәдәният турындагы законнары нигезендә балаларны һәм яшьләрне бөтен дөнья һәм милли, матди һәм рухи мәдәният казанышлары белән, гомумкешелек хәзинәләре һәм яңа технологияләр белән таныштыру максатларында, тормыш мәгънәсенә төшенүдә ярдәм итү йөзеннән:

мәдәният учреждениеләрен һәм милли үзәкләрне төзү һәм үстерү өчен, тарих һәм архитектура һәйкәлләрен торгызу өчен шартлар тудыра; республиканың җәмгыяви-мәдәни мөмкинлекләрен эзлекле рәвештә үстерү өчен кирәкле шартлар булдыра;

мәдәният, фән һәм техника казанышларын пропагандалау турында, яшьләрнең ялын оештыру хакында кайгырта, балалар һәм яшьләр өчен кино-, теле-, радио- һәм башка программалар булдыра;

яшь үзенчәлекләренә һәм шәхси үзенчәлекләренә карап, мәгълүмат эзләүдә, аны эшкәртүдә һәм үзләштерүдә белгечлек ярдәме күрсәтә; балалар, яшүсмерләр һәм яшьләр өчен әдәбият чыгара;

яшь гражданнарның әдәбият, сәнгать һәм халыкчан кәсепләр белән шөгыльләнүен хуплый.

Яшьләрнең буш вакытларын һәм үзара аралашуларын оештыруда күпкырлы ихтыяҗларын һәм активлыгын үстерүдә ярдәм итәр өчен яшьләр клублары оештырыла. Дәүләт аларның эшчәнлеге өчен шартлар тудыра.

2. Дәүләт балаларның һәм яшүсмерләрнең тору урыннарындагы җәмгыяви-педагогик әдәпсезлеген, күзәтүчесезлеген, тәрбиячесезлеген бетерү буенча тиешле гамәлләрне тормышка ашыра, яшүсмерләр һәм яшьләр арасында ял итүнең җәмгыятькә каршы, хокук бозуга юнәлдерелгән рәвешләре таралуга каршы тора.

3. Халык депутатларының җирле Советлары предприятиеләрдәге, оешмалардагы һәм учреждениеләрдәге һәр эшләүче өчен, аларга балаларына һәм гаиләләренә лаеклы яшәү тирәлеге булдыру максатларында,гамәлдәге салым системасы нигезендә әлеге эшче яши торган комплексның, микрорайонның, поселокның һәм башкаларның җирле җәмәгатьчелекнең үзидарә органы фондына шушы предприятиеләрдән, оешмалардан һәм учреждениеләрдән түләүләр кертүне билгели ала.

4. Хакимиятнең һәм идарәнең җирле органнары, предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләр балалар һәм яшьләр өчен үзләренә караган түбәндәге учреждениеләр төзүне һәм тотуны тәэмин итәләр:

яшьләр өчен сарайлар, үзәкләр,йортлар һәм бүлмәләр;

яшьләр клублары һәм спорт клублары;

яшь техниклар һәм яшь натуралистлар станцияләре;

иҗат үзәкләре;

яшьләр өчен турист базалары, кемпинглар һәм станцияләр;

пионер җәйләүләре;

хезмәт һәм ял өчен җәйге җәйләүләр;

ял итүне, каникулларны һәм яшьләр туризмын тәэмин итүче башка учреждениеләр.

<u>18 статья.</u> Физик тәрбия һәм спорт үсешенә дәүләт ярдәме

Дәүләт физик тәрбия һәм спорт турындагы закон һәм программалар нигезендә:

балаларга һәм яшьләргә сәламәтлекләрен ныгыту һәм саклау өчен физик тәрбия һәм спорт белән шөгыльләнү хокукын гарантияли һәм мөмкинлекләр тудыра;

физик һәм спорт тәрбиясен гамәлгә ашыра;

спортның техник төрләрен үстерүне тәэмин итә;

дәүләтнеке һәм дәүләтнеке булмаган физик тәрбия-спорт учреждениеләре оештыруны һәм үстерүне хуплый һәм аңа ярдәм итә;

балаларны, яшүсмерләрне һәм яшьләрне сәламәтләндерүнең мәтди нигезләрен саклау һәм ныгыту, аны әлеге һәм соңыннан булачак милек хуҗалары тарафыннан башка максатларда файдалануга юл куймау өчен икътисадый һәм хокукый саклау гамәлләрен тормышка ашыра;

мәдәният һәм спорт объектларын төзүне һәм тотуны тәэмин итә.

19 статья. Яшь гражданнарның сәламәтлек саклау өлкәсендәге хокукларын тәэмин итү

Дәүләт органнары яшьләргә [illegible] хезмәт, уку һәм көнкүреш өчен сәламәт шартлар тудыра, аларның сәламәтлеген саклауны эзлекле рәвештә үстерүне тәэмин итә, моның өчен:

яшьләрнең сәламәтлеген даими күзәтү һәм аларга медицина хезмәте күрсәтү оештырыла;

яшь гарип гражданнарның җәмгыяви яраклашуы, аларга медицина хезмәте һәм җәмгыяви хезмәт күрсәтү, аларны һөнәргә өйрәтү тәэмин ителә һәм аларның җәмәгать тормышында актив катнашуы өчен алшартлар тудырыла;

кайбер авырулар вакытында яшьләрнең исемсез /аноним/ медицина тикшерүе узу һәм дәвалану хокукы таныла һәм тәэмин ителә;

мәктәпләрдә, студент ашханәләрендә, яшьләрнең тулай торакларында туклануны яхшырту турында кайгырта;

республикадагы икътисадый вәзгыятьне исәпкә алучы җәмгыяви

түләүләр һәм ташламалар системасы камилләштерелә.

## 4 бүлек. Яшь гражданнарның икътисадый мөстәкыйльлеген хуплау

### 20 статья. Яшь гражданнарның икътисадый мөстәкыйльлеген тәэмин итү һәм хуплау

I. Татарстан Республикасы яшьләргә үзләренең хезмәткә булган сәләтләреннән файдалану мөмкинлекләрен киңәйтү, яшь гражданнарның эшкуарлык эшчәнлеген хуплау, салым салуда һәм кредит бирүдә ташламалар бирү, акцияләргә, башка кыйммәтле кәгазьләргә һәм банк учреждениеләренә кертелгән байлыклардан табыш алу юлы белән яшьләрнең икътисадый хокукларын гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыра.

Дәүләт яшь гражданнарның инициативалы шәхсән һәм күмәк эшчәнлекләрен түбәндәге юнәлешләр буенча хуплый һәм ярдәм итә:

матди һәм рухи хәзинәләр булдыру;

фәнни һәм техник фикерләрне әзерләү һәм гамәлгә ашыру;

яшьләрнең торак комплексларын төзү;

яңа җәмгыяви технологияләр булдыру;

мөстәкыйльлекне һәм иҗтимагый үзидарәнең төрле рәвешләрен үстерү.

2. Яшь гражданнарга түбәндәгеләр гарантияләнә;

эшкуарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау;

матди, әйберләтә, акчалата, хезмәт һәм мәгълүмат рәвешендәге һәм табигый байлыклардан файдалану мөмкинлеге;

дәүләт предприятиеләренең һәм милекнең башка рәвешләренә нигезләнгән предприятиеләрнең милкәтен сатып алуда, дәүләт милкәтен һәм җирле милкәтне дәүләттән аерганда һәм аларны хосусыйлаштырганда, милкәтне үз милкенә алганда тигез мөмкинлекләр;

гамәлдәге законнарны аңлату һәм гамәлгә кую документларын әзерләү буенча укыту-консультация үзәкләрендә мәгълүмат һәм консультация хезмәте күрсәтелү.

Яшь гражданнар үзләренең эшчәнлегендә эшкуарлык өлкәсендәге һәр төрле хәвеф-хәтәр һәм үз проектлары өчен законнар нигезендә җаваплы булалар.

3. Заманча проектларны һәм программаларны гамәлгә ашыруда яшьләрне җәлеп итү өчен дәүләт инновацион үзәкләр челтәре төзүне тәэмин итә.

4. Законнарда билгеләнгән махсус очраклардан гайре, яшь гражданнарның турыдан-туры яисә читләтеп хезмәткә хокукларын чикләү, шул исәптән эш бирүгә һәм эштә күтәрелүгә, хезмәт өчен түләүгә бәйле рәвештә чикләүләр, эш стажына яисә хезмәткәрнең яшенә бәйле рәвештә хезмәт турында килешүләрне өзү кебек чикләүләр законсыз дип таныла.

5. Фермерлыкны һәм яшьләрнең авылны торгызуга һәм үстерүгә юнәлдерелгән башка инициативаларын дәүләт терлек, кече механизация чаралары сатып алуга, җир сатып алуга, җир салымын салуга, аренда түләвенә ташламалар бирү юлы белән җайга сала.

<u>2I статья.</u> Яшьләр предприятиеләренә дәүләт ярдәме

I. Коллективта эшләүчеләрнең 75 процenттан да ким булмаган өлеше яшь гражданнар булган шәхси, күмәк предприятиеләр, гаилә предприятиеләре, шулай ук әлеге предприятиеләрнең берләшмәләре яшьләр предприятиеләре дип таныла.

2. Татарстан Республикасы яшьләр предприятиеләрен җәмгыяви-икътисадый, оештыру, хокукый яклау буенча түбәндәге ча-

ралар системасын билгели:

яшьләр предприятиеләренә салым салу һәм кредит бирүдә, кирәкле җитештерү чаралары һәм җитештерү биналары белән тәэмин итүдә ташламалар бирү;

аларның сәүдәгәрлек тәвәккәллеген иминләштерү;

җаваплылыкны үз өстенә йөкләү турында тиешенчә эшләнгән кәгазьләр һәм гарантияләр бирү;

яшь гражданнарны эшкуарлык эшчәнлегенә өйрәтүне финанслау;

башка чаралар.

3. Мәктәп укучыларының, төрле уку йортларындагы көндезге бүлек укучыларының, студентларының укудан тыш вакытларда эшләгән яисә уку-җитештерү барышы белән бәйле эш өчен түләнгән хезмәт хакы җәмгыяви иминлеккә, Пенсия фондына, Хезмәт белән тәэмин итү фондына түләүләрдән һәм керемгә салына торган салымнан азат ителә.

4. Татарстан Республикасы Хөкүмәте һәм халык депутатларының җирле Советлары яшьләр предприятиеләрен теркәү өчен җыемнар түләү буенча ташламалар билгели.

<u>22 статья.</u> Яшь гражданнарны хезмәт белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт ярдәме

I. Дәүләт яшь гражданнарга, аларның омтылышларын, сәләтләрен һәм белгечлек дәрәҗәләрен исәпкә алып, эшкә урнаштыруда, алар өчен буш эшче урыннар оештыруда, эшлексез белем бирүдә, белгечлекләрен күтәрүдә һәм эшсезлек дәрәҗәсен кыскарту буенча башка чаралар күрүдә һәръяклап ярдәм итә.

2. Хезмәт һәм эш белән тәэмин итү органнарында эшсез яшь гражданнарга ярдәм күрсәтү буенча махсус бүлекчәләр төзелергә мөмкин.

Эшсез калган яшь гражданнарга яшьләрнең җәмәгать оешмалары һәм дәүләткә карамаган башка оешмалар тарафыннан ярдәм күрсәтелергә мөмкин.

3. Яшьләрне эшкә урнаштыруга кагылышлы тәкъдимнәрдән 30 яше тулган затлар да тиешле күләмдә файдалана ала.

4. Кадрларны хезмәткә әзерләү челтәре нигезендә дәүләт органнары һөнәргә өйрәтү, белгечлекләрен күтәрү, яшь гражданнарны стажировкалау һәм яңадан укыту /шул исәптән чит илдә дә/ буенча комплекслы программалар әзерли һәм гамәлгә ашыра.

5. 5.I. Дәүләт яшь гражданнарның беренчел эш белән тәэмин ителүгә яисә матди компенсация күрсәтелүгә хокукын тәэмин итә.

5.2. Хезмәт турында Татарстан Республикасы законнары нигезендә хакимиятнең республика һәм җирле органнары гомуми урта белем мәктәпләрен, техник һөнәр училищеларын, махсус урта һәм югары уку йортларын тәмамлаучы яшьләрне, шулай ук яше 20 яшьтән түбәнрәк булган башка затларны эшкә кабул итү өчен квота билгели.

<u>23 статья.</u> Балигъ булмаганнарның хезмәте

I. Татарстан Республикасында ата-аналарның яисә аларны алмаштыручы затның ризалыгы, шулай ук балалар һәм яшьләр мәнфәгатьләре буенча тиешле органның ризалыгы белән I3 яше тулган балигъ булмаган балаларны укудан тыш вакытта көче җитәрлек эшкә

урнаштыру рөхсәт ителә.

Эш шартлары һәм рәвеше сәламәтлеккә зыян китермәскә һәм укыту барышын бозмаска тиеш.

2. Дәүләт эш белән тәэмин итүче,мәктәп белән җитештерү өлкәсен якынайтучы, мәктәп каникуллары чорында һәм укудан тыш вакытта балигъ булмаганнар өчен эш урыннары булдыручы предприятиеләрне һәм оешмаларны кызыксындыру чараларын күрә.

3. Балигъ булмаганнарның хезмәтеннән файда күрү өчен яисә тиешенчә түләмичә файдалану тыела.

4. I8 яше тулмаган затларны эшкә алу тәртибе һәм хезмәтне саклау буенча таләпләр хезмәт турындагы законнарда билгеләнә.

5 бүлек

Яшьләр оешмаларының эшчәнлеге

<u>24 статья.</u> Яшьләр оешмаларының хокукый статусы

I. Яшьләр оешмаларының хокукый статусы иҗтимагый берләшмәләр турында гамәлдәге законнар, шулай ук әлеге Закон һәм шуның нигезендә республика һәм җирле органнар тарафыннан чыгарыла торган норматив актлар белән билгеләнә.

2. 2.I. Мөстәкыйль берләшмәләр яисә Татарстан Республикасының районнары һәм шәһәрләре территориясенең иң кимендә яртысында яисә республика халкының кимендә яртысы яши торган территориясендә җирле бүлекчәләре булган ачык типтагы демократик төзелмәле җәмгыятьләр республика яшьләр оешмалары дип танына.

Билгеле бер яшькә җиткәч, аларда әгъза булуны туктату

яшьләр оешмалары уставының мәҗбүри таләбе булып тора. Яшьләр оешмалары әлеге таләптән үзләренең әгъзалары өчен искәрмәләр ясарга хаклы, әмма аларның саны бу оешмадагы әгъзаларның 25 процентыннан артмаска тиеш.

2.2. Яшьләр оешмаларына шулай ук аларның төрле берләшмәләре керә.

3. 3.I. Билгеләнгән тәртиптә теркәлү үткән яшьләр оешмалары хокукый зат хокукына ия булалар.

3.2. Яшьләр оешмаларын теркәү өчен түләү иҗтимагый оешмалар өчен билгеләнгән теркәү җыемының 50 процентыннан да арта алмый.

4. 4.I. Яшьләр оешмалары һәм аларның берләшмәләре яшь гражданнар мәнфәгатьләрен чагылдыралар һәм алар исеменнән эш йөртәләр.

4.2. Бер генә яшьләр оешмасы да Татарстан Республикасының барлык яшь гражданнары ихтыяҗларын һәм мәнфәгатьләрен үзе генә чагылдыруга дәгъва итә алмый.

5. 5.I. Яшь гражданнарны яшьләр оешмаларына керүгә турыдан-туры яисә читләтеп мәҗбүр итү тыела.

5.2. Яшь гражданның иҗтимагый берләшмә эшчәнлегендә катнашуы яки катнашмавы аның хокукларын һәм ирекен чикләү өчен нигез була алмый.

5.3. Бу оешмаларда яшь гражданнарда башка идеологияләргә дошманлык, аларны кабул итмәү рухында тәрбияләү тыела.

5.4. Фиркаләр, иҗтимагый-сәяси һәм җәмәгать оешмалары,

шул исәптән балалар, яшүсмерләр һәм яшьләр оешмалары, массакүләм мәгълүмат чаралары һәм аерым затлар балаларны, яшүсмерләрне һәм яшьләрне, хокук бозып, җинаятьчел эшчәнлеккә яисә Конституциягә каршы юнәлдерелгән сәяси, иҗтимагый сәяси оешмаларга җәлеп иткән өчен, шулай ук балаларны, яшүсмерләрне һәм яшьләрне җинаятьчел социальләштерүгә омтылган өчен законнар нигезендә җаваплы булалар.

5.5. Балаларны һәм яшүсмерләрне хәрби вакыйгаларда һәм коралллы бәрелешләрдә файдалану тыела.

5.6. Җинаятьчел төркемнәрдә һәм оешмаларда катнашучы 10 яшьтән олырак балаларның чикләнгән җаваплылыгы турындагы мәсьәләне дәүләт хәл итә.

6. Республикада балалар һәм яшьләр хәрәкәтләре, ассоциацияләр, халыкара һәм республикаара оешмаларның бүлекчәләре һәм секцияләре, вәкаләтле сайланган органнары, иҗтимагый берләшмәләр турында гамәлдәге законнарда каралган хокукларга ия булган башка берләшмәләр эшли ала.

7. Яшьләр оешмалары устав бурычларын гамәлгә ашыру өчен гамәлдәге законнар нигезендә юридик зат хокукына ия булган предприятиеләр һәм оешмалар төзи алалар.

### 25 статья. Яшьләр оешмаларының дәүләт һәм төбәк яшьләр сәясәтен әзерләүдә катнашуы

Дәүләт идарәсе органнары, яшьләр оешмаларының җитәкче органнары белән алдан киңәшеп, тиешле яшьләр оешмаларының устав бурычларын үз эченә ала торган яшьләр мәсьәләләре буенча карарлар кабул итәләр. Әлеге максатларда дәүләт идарәсе органнары үз вакытында, карар кабул итәргә иң кимендә 3 көн кала,

үзләре әзерләгән карар проектлары, шулай ук кирәкле аңлатмаларны һәм белешмә материалларны яшьләр оешмаларының җитәкче органнарына җибәрәләр. Консультацияләр яшьләр оешмалары тарафыннан үзләренең фикерләрен һәм тәкъдимнәрен язма рәвештә бәян итү юлы белән дә, шулай ук уртак киңәшмәләр /утырышлар/ уздыру рәвешендә дә була. Дәүләт идарәсе органнары һәм яшьләр оешмаларының җитәкче органнары уртак карар нигезендә мондый консультацияләр уздыруның килешенгән тәртибен билгели алалар.

Яшьләр оешмалары эшчәнлегенә кагылышлы мәсьәләләр буенча карарлар дәүләт идарәсе органнары тарафыннан әлеге яшьләр оешмасының тиешле җитәкче органы катнашында кабул ителә.

Дәүләт идарәсе органнары яшьләр оешмаларының тиешле баскычтагы җитәкче органнарының тәкъдимнәрен һәм күрсәтмәләрен бер ай эчендә карарга һәм карау нәтиҗәләре буенча дәлилле карарлар кабул итәргә һәм бу хакта алда күрсәтелгән органнарга хәбәр итәргә тиеш.

26 статья. Яшьләр оешмалары эшчәнлегенә гарантияләр

I. Әлеге Закон һәм норматив актлар нигезендә дәүләт органнары һәм җирле органнар балалар һәм яшьләр оешмаларына хокукый, финанс һәм матди ярдәм күрсәтә алалар, бу, беренче чиратта, яшьләр оешмаларының үзләренең шәхси хуҗалык эшчәнлегеннән ала торган һәм дәүләт яшьләр сәясәтенең расланган программаларын гамәлгә ашыруга тотыла торган табышларын /керемнәрен/ салым салынудан азат итү рәвешендә була.

2. Дәүләт яшь гражданнарның яшьләр оешмалары эшчәнлегенә, башка оешмалардагы яшьләр секцияләрен дә кертеп, керүләрен һәм катнашуларын хуплый.

3. Дәүләт милли яшьләр оешмаларының халыклар арасындагы дуслыкны һәм хезмәттәшлекне ныгытуга юнәлтелгән эшчәнлегенә ярдәм итә.

4. Балалар һәм яшүсмерләр оешмалары һәм аларның предприятиеләре табышка салымнан азат ителәләр.

Яңа оешкан яшьләр оешмалары һәм яшьләр предприятиеләре теркәлү үткәннән соң баштагы ике елда табышка салым түләүдән азат ителәләр, ә аннан соңгы елда табышка салым күләме 50 процентка кими.

5. Хакимиятнең республика һәм җирле органнары балалар һәм яшьләр оешмаларына аларның эшчәнлеген тәэмин итү өчен тиешле бюджет акчаларыннан субсидияләр бирәләр /әгәр әлеге яшьләр оешмасына башка җәмәгать оешмалары яисә предприятиеләре, оешмалары һәм учрежлениеләре тарафыннан кайтарып бирмәү шарты белән акча бирелмәгән булса/, шулай ук мәктәп биналарыннан, мәктәптән тыш учреждениеләрдән, клублардан, мәдәният йортларыннан, спорт корылмаларыннан һәм башка корылмалардан файдалану хокукы да бирелә: балалар оешмаларына - бушлай, ә яшьләр оешмаларына гамәлдәге законнар нигезендә ташламалы шартларда.

6. Хакимиятнең һәм идарәнең республика һәм җирле органнары, предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләр яшьләр оешмалары милкенә бушлай яисә ташламалы шартларда биналар, корылмалар, элемтә һәм йөртү чаралары, устав бурычларын үтәү өчен кирәкле башка мөлкәт бирә алалар.

6 бүлек

Дәүләтнең яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны оештыру чаралары

27 статья. Дәүләтнең яшьләр сәясәтен тәэмин итү

I. Җәмгыяви һәм икътисадый үсешнең республика, төбәк һәм җирле программаларында яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру буенча максатчан гамәлләр үткәрү күздә тотыла.

2. Республика һәм җирле бюджетларның тиешле бүлекләрендә яшьләр сәясәте өлкәсендәге гамәлләрне финанслау өчен кирәкле ассигнованиеләр бирү карала.

Дәүләтнең һәм төбәкнең яшьләр сәясәтен тәэмин итүгә бюджет чаралары бүленгәндә яшь граждан булып җитешү һәм үсү өчен кирәкле фәнни нигезләнгән җәмгыяви нормалар һәм нормативлар исәпкә алына.

28 статья. Яшьләр сәясәте өлкәсендә дәүләт идарәсе

I. I.I. Татарстан Республикасында закон чыгару, башкарма, хөкем һәм җирле үзидарә хакимияте каршында махсус төзелмәләр булдырыла һәм яшь гражданнарның ихтыяҗларын һәм аларның хокукларын яклау үзенчәлекләрен исәпкә алуны тәэмин итүче органнарның эшчәнлеге тәртибе билгеләнә.

I.2. Дәүләтнең яшьләр сәясәтен оештыру һәм гамәлгә ашыру һәм яшь гражданнарның үсешен һәм тиешенчә җәмгыяви аякка басуын тәэмин итү өчен Татарстан Республикасында балалар һәм яшьләр мәнфәгатьләре буенча дәүләт хезмәте төзелә, аның составына,

үзенең органнарыннан башка, түбәндәгеләр дә кирә:

Балигъ булмаганнарның һәм яшьләрнең хокукларын саклау инспекциясе;

балалар һәм яшьләр өчен төрле юнәлештәге җәмгыяви хезмәтләр;

башка төзелмәләр.

I.3. Коллективларының күбрәк өлешен яшь гражданнар тәшкил итә торган предприятиеләрдә, оешмаларда, учреждениеләрдә, уку йортларында яшьләр белән эшләү буенча тиешле хезмәтләр /төзелмәләр/ төзелергә мөмкин.

2. Законнарда каралган очракларда, аларда билгеләнгән тәртиптә һәм чикләрдә барлык норматив-хокукый актлар һәм республикада хакимият һәм идарә органнарының яшь гражданнар мәнфәгатьләренә кагылышлы карарлары балалар һәм яшьләр мәнфәгатьләре буенча тиешле органнарның бәяләмәсе яисә тәкъдиме буенча килешенеп кабул ителә.

3. Яшьләргә кагылышлы мәсьәләләрне әзерләү һәм алдан карау өчен, карарлар үтәлешен тәэмин итү һәм аларны тормышка ашыруны тикшереп тору өчен халык депутатлары Советлары балалар һәм яшьләр мәнфәгатьләре буенча даими комиссияләр төзиләр.

Комиссияләрнең эшчәнлеге тәртибе һәм аларның вәкаләтләре Татарстан Республикасы законнары, халык депутатларының тиешле Советлары карарлары тарафыннан билгеләнә.

4. 4.I. Яшьләр сәясәте өлкәсендә дәүләт идарәсе Татарстан Республикасының Балалар һәм яшьләре мәнфәгатьләре буенча дәүләт комитеты һәм җирле үзидарәнең тиешле органнары тарафыннан га-

мәлгә ашырыла.

4.2. Балалар һәм яшьләр мәнфәгатьләре буенча идарә органнары җитәкчеләре Закон билгеләнгән тәртиптә халык депутатлары Советы рөхсәте белән билгеләнеп куела.

4.3. Балалар һәм яшьләр мәнфәгатьләре буенча органнар балалар һәм яшьләр мәнфәгатьләре буенча тиешле даими депутат комиссиясе карамагына түбәндәгеләрне кертә:

дәүләтнең яшьләр сәясәтен, җирле яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру буенча үз вәкаләтләре чорына эшчәнлек программасын;

балалар һәм яшьләр тормышының төрле аспектлары турында мәгълүмат;

үзенең эшчәнлеге хакында кимендә елга бер мәртәбә нотык.

29 статья. Яшьләр мәнфәгатьләре, физик тәрбия һәм спорт буенча Татарстан Республикасы Югары Советы даими комиссиясе

Яшьләр мәнфәгатьләре, физик тәрбия һәм спорт буенча Татарстан Республикасы Югары Советы даими комиссиясе Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Закон, "Татарстан Республикасы Югары Советының даими комиссияләре турында" Татарстан Республикасы Законы нигезендә:

Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәтенең өстенлекле юнәлешләренң республикадагы балалар һәм яшьләр оешмаларының тәкъдимнәрен исәпкә алып, балалар һәм яшьләр хәрәкәте концепциясен эшли;

комплекслы һәм максатчыл программаларны, дәүләтнең яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру өлкәсендә фәнни нигезләнгән матди-техник, финанс-бюджет, җәмгыяви нормаларны һәм норматив-

ларны эшләүдә һәм раслауда катнаша;

республиканың балалар һәм яшьләр мәсьәләләре белән шөгыльләнүче министрлыклары, ведомстволары, төрле оешмалары һәм учреждениеләре арасында бюджет ассигнованиеләрен бүлүне алдан карый;

дәүләтнең яшьләр сәясәтен гамәлгә ашырганда яшь гражданнарга, яшь гаиләләргә, балалар һәм яшьләр оешмаларына дотацияләр, субсидияләр, кредитлар бирү, башка оешмаларга, предприятиеләргә һәм берләшмәләргә ташламалар бирү тәртибе турында, шулай ук финанслау тәртибен һәм башкарма органнарны матди кызыксындыру тәртибе турында тәкъдимнәр кертә яисә аларны бирү тәртибен килештерә.

Татарстан Республикасы Югары Советы һәм аның органнары тарафыннан кабул ителү өчен әзерләнә торган закон проектларына, шулай ук башка актларга яшь гражданнарның үсеше, җәмгыяви аякка басу буенча һәм аларның төрле катламдагы тормыш эшчәнлегенең башлангыч /старттагы/ шартларын тигезләү буенча, балаларның һәм яшьләрнең җәмгыять өчен файдалы эшчәнлеген җайга салу буенча җәмгыяви-икътисадый, хокукый, оештыру чараларын күздә тотучы төзәтмәләр һәм тәкъдимнәр, шулай ук җәмгыяви чигенүләрне профилактикалауга һәм яшь гражданнарны уңышсыз категорияләрдән чыгаруга юнәлтелгән чараларны күздә тотучы тәкъдимнәр, төзәтмәләр кертә;

дәүләтнең яшьләр сәясәте мәсьәләләре буенча парламентара алмашулар тәртибендә халыкара һәм республикара элемтәләр урнаштыра;

Балалар һәм яшьләр мәнфәгатьләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитеты рәисе урынына, шулай ук Физик

тәрбия һәм спорт буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитеты, Татарстан Республикасының халык мәгарифе министрлыгы һәм мәдәният министрлыгы җитәкчеләре урынына кандидатуралар буенча бәяләмәләр бирә;

Балалар һәм яшьләр мәнфәгатьләре буенча дәүләт комитетын төзи һәм аның эшчәнлеге мәсьәләләрен карый;

дәүләтнең яшьләр, балалар һәм гомум хокук сәясәте өлкәсендә республиканың, башка төбәкләрнең һәм чит илләрнең закон чыгару эшчәнлегенә кагылышлы мәсьәләләре буенча, закон чыгару эшчәнлеге механизмнары һәм аны гамәлгә ашыру тәҗрибәсе буенча /шул исәптән урыннарда/ хокукый әдәбият китапханәсен оештыра;

законнар нигезендә башка вәкаләтләрне башкара.

<u>30 статья.</u> Балалар һәм яшьләр мәнфәгатьләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитеты.

I. Балалар һәм яшьләр мәнфәгатьләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитеты үз вәкаләтләре чикләрендә түбәндәге вазыйфаларны үти:

яшьләр сәясәтенә тармакара идарәне тәэмин итү һәм яшь гражданнарның хокукларын һәм законлы ихтыяҗларын үтәү буенча республика министрлыкларының һәм ведомстволарының эшчәнлеген җайга салу;

дәүләтнең яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру, үстерү һәм камилләштерү буенча комплекслы һәм максатчыл программаларның, җәмгыяви нормаларның һәм нормативларның проектларын эшләү;

балалар һәм яшьләр мәсьәләләре буенча фәнни тикшеренүләр уздыруны, шулай ук проектларга һәм программаларга бәйсез экспертиза ясауны тәэмин итү;

дәүләтнең яшьләр сәясәте өлкәсендәге гамәлләрне шулар өчен каралган бюджет акчалары һәм бюджеттан тыш акчалар исәбеннән финанслауны гамәлгә ашыру; әлеге акчаларны тотуны һәм куллануны тикшереп тору;

Татарстан Республикасы Югары Советының Яшьләр мәнфәгатьләре, физик тәрбия һәм спорт буенча комиссиясенә үзенең проектларын тапшыру;

хөкүмәт тарафыннан республика Югары Советына бирелә торган еллык хисапка балалар һәм яшьләрнең хәле, яшь гражданнарга ярдәм күрсәтү планы һәм ирешелгән уңышлар турында, әлеге Законны куллану тәҗрибәсенең нәтиҗәләре хакында аерым бүлек кертү;

урыннарда, Татарстан Республикасы территориясендәге хәрби частьләрдә һәм учреждениеләрдә җирле һәм төбәк яшьләр сәясәтен уздыруда фәнни-методик ярдәм, оештыру һәм мәгълүмат белән ярдәм итү;

республикада дәүләтнең яшьләр сәясәтен кадрлар белән тәэмин итү мәсьәләсен хәл итү;

балалар һәм яшьләр мәнфәгатьләре буенча җирле органнар тарафыннан, шулай ук предприятиеләр һәм оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырыла торган балалар һәм яшьләр программаларын /әгәр алар республика әһәмиятенә ия булсалар һәм үзенчәлекләре буенча балалар һәм яшьләр мәнфәгатьләре буенча җирле орган тарафыннан нәтиҗәле тәэмин ителә алмаганда/хуплау һәм аларны тормышка ашыруда ярдәм күрсәтү;

яшь гражданнарның рухи үсешен яклау мәсьәләләре буенча дини оешмалар белән үзара мөнәсәбәт;

балалар һәм яшьләр өчен кирәкле һәм җитәрлек санда дәүләтнеке булмаган учреждениеләр булганда, хезмәт күрсәтелгәндә һәм гамәлләр үткәрелгәндә, үз гамәлләрен тормышка ашырудан баш тарту;

яшь гражданнарның һөнәргә ирешүләрендә һәм эшкә урнашуда ярдәм итү;

яшь гражданнарга инновацион иҗади эшчәнлек өчен, аларның ихтыяҗларын тулысынча канәгатьләндерү өчен уңайлы шартлар булдыру;

яшь гражданнарга Закон тарафыннан бирелгән хокукларын аңлату һәм консультацияләр уздыру;

милек рәвешләренә һәм нинди ведомствога буйсынуына карамастан, предприятиеләрдә, оешмаларда, учреждениеләрдә, шулай ук республика территориясендәге хезмәт белән тәрбияләү һәм хезмәт белән төзәтү учреждениеләрендә дә яшь гражданнарның, шул исәптән яшь хәрби хезмәткәрләрнең хокукларын һәм законлы ихтыяҗларын үтәүне тикшереп тору;

яшь гражданнарны хәрби хезмәт узу өчен әзерләүдә ярдәм итү;

караучысыз һәм тәрбиячесез калган балигъ булмаганнар өчен ятимнәр йорты эшен оештыру;

карау-кайгыртуны һәм тәрбия итүне оештыруны үз вәкаләтләре чикләрендә тикшереп тору;

республиканың яшьләр оешмалары белән турыдан-туры элемтәне һәм хезмәттәшлекне тормышка ашыру, аларга тиешле ярдәм күрсәтү;

теркәлү үткән яшьләр оешмаларына һәм яшь гражданнарга җәмгыяви һәм матди ярдәм күрсәтүче башка оешмаларга, учреждениеләргә дотацияләр, субсидияләр бирү;

яшь гражданнарның законнар нигезендә җәмәгать тәртибен саклауда һәм хокук бозуларны кисәтүдә ирекле рәвештә катнашуларын киңәйтүгә ярдәм итү;

мөстәкыйль үсешнең төрле рәвешләренә булышлык итү;

эш бирүчеләрнең /милекчеләрнең яисә алардан вәкаләт алган органнарның/ вәкилләре белән профсоюзларның тиешле территориядәге һәм тармактагы берләшмәләре арасында яшь хезмәткәрләрне җәмгыяви-икътисадый яклау, аларның хезмәтләрен саклау һәм яшь хезмәткәрләрне эштә файдалану буенча гамәлләрне күздә тотучы төп килешүләр төзү;

билгеләнгән тәртиптә предприятиеләр, оешмалар, фондлар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары оештыру;

яшьләр сәясәте өлкәсендәге статистик мәгълүматларны анализлау;

дәүләтнең яшьләр сәясәте өлкәсендә игътибарга лаек хезмәтләр күрсәткән затлар Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләре белән бүләкләү өчен тәкъдимнәр кертү;

дәүләтнең яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча халыкара һәм республикаара элемтәләр урнаштыру һәм тәҗрибә уртаклашу;

әлеге Законга, Балалар һәм яшьләр мәнфәгатьләре буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә, башка норматив актларга таянып, бүтән вазыйфаларны үтәү.

2. Балалар һәм яшьләр мәнфәгатьләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитетының үз вәкаләтләре чикләрендә бастырып чыгарылган актлары Татарстан Республикасы территориясендә катгый үтәлергә тиеш.

3. Дәүләт комитеты үзенә йөкләнгән идарә итү өлкәсенең торышы өчен әлеге Закон, башка норматив актлар нигезендә Татарстан Республикасы Президенты, Югары Советы һәм Хөкүмәте каршында җаваплы була.

4. Балалар һәм яшьләр мәнфәгатьләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитеты рәисе Татарстан Республикасы Хөкүмәте әгъзасы була, ул комитет эшчәнлегенә җитәкчелек итә, әлеге Закон һәм башка норматив актлар нигезендә аның эшен оештыра һәм комитет исеменнән эш йөртә.

5. Балалар һәм яшьләр мәнфәгатьләре буенча дәүләт комитеты юридик зат хокукына ия, аның Дәүләт туграсы булган һәм үз исеме язылган мөһере бар.

31 статья. Балалар һәм яшьләр мәнфәгатьләре буенча җирле органнар

1. Балалар һәм яшьләр мәнфәгатьләре буенча җирле идарә органнары җирле үзидарә турында законнарда, әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә, халык депутатларының җирле Советлары һәм администрация башлыклары карарлары нигезендә төзеләләр һәм үзләренең эшчәнлеген гамәлгә ашыралар, шулай ук:

яшь гражданнарның үсешен билгеләүче һәм җирле бюджетлар, бюджеттан тыш фондлар һәм башка акча хисабына яшь гражданнарга җәмгыяви ярдәм һәм хезмәт күрсәтүнең минималь дәрәҗәсен ныгы-

тучы нормаларны һәм нормативларны күтәрү турында тәкъдимнәр кертәләр;

яшь гражданнарга билгеләнгән дотацияләр, субсидияләр, кредитлар бирәләр;

яшь гражданнарның яшәү урыннарында үзидарәнең төрле рәвешләрен үстерүгә ярдәм итәләр;

җирле хакимият һәм идарә органнары тарафыннан балалар һәм яшьләр өчен бирелә торган торакны, мәктәпкәчә балалар учреждениеләрендә урыннарны бүлүдә һәм башка төр хезмәт күрсәтүләрдә катнашалар;

балигъ булмаганнарга, махсус җәмгыяви ярдәмгә мохтаҗ башка гражданнарга турыдан-туры көндәлек һәм күпьяклы җәмгыяви ярдәм күрсәтүне тәэмин итәләр;

балалар һәм яшьләр өчен киң күләмдә гамәлләр оештыралар;

башка вазыйфаларны һәм вәкаләтләрне тормышка ашыралар.

2. Балалар һәм яшьләр мәнфәгатьләре буенча җирле органнар юридик зат хокукына ия була алалар.

**32 статья.** Балигъ булмаганнарның һәм яшьләрнең хокукларын саклау инспекциясе

1. Татарстан Республикасында балигъ булмаганнарның һәм яшьләрнең хокукларын саклау инспекциясе:

предприятиеләрдә, оешмаларда һәм учреждениеләрдә, шул исәптән балалар, хезмәт белән тәрбияләү һәм хезмәт белән төзәтү учреждениеләрендә, хәрби оешмаларда яшь гражданнарның хокукларын һәм законлы ихтыяҗларын үтәүне тикшереп тора;

тиешле органнар белән берлектә балаларны һәм яшьләрне карау-күзәтү һәм тәрбияләү эшләрен башкара;

яшь гражданнарның хокукларын һәм законлы ихтыяҗларын яклау турындагы дәгъва белән судка мөрәҗәгать итә;

гамәлдәге законнарда каралган башка вазыйфаларны үти.

2. Инспекцияне оештыру тәртибе Балалар һәм яшьләр мәнфәгатьләре буенча дәүләт комитеты тәкъдиме нигезендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

33 статья. Балалар һәм яшьләр өчен җәмгыяви хезмәтләр

1. Балалар һәм яшьләр өчен җәмгыяви хезмәтләр түбәндәге вазыйфаларны башкаралар:

яшь гражданнарга аларның хокуклары, мөмкинлекләре һәм бурычлары турында мәгълүмат бирү;

җәмгыяви хезмәткәрләр әзерләү;

балигъ булмаганнарга, башка яшь гражданнарга һәм аларның ата-аналарына консультацияләр бирү;

хокукый, җәмгыяви, психологик, наркологик һәм башка ярдәм күрсәтү;

яшь гражданнарга һәм гаиләләргә, аларның үзләренең вазыйфаларын үтәү мөмкинлекләрен һәм аларның керем дәрәҗәсен исәпкә алып, ярдәм күрсәтү;

гаиләдә, балалар учреждениеләрендә һәм мәктәптән тыш учреждениеләрдә тәрбияләүгә ярдәм күрсәтү;

яшь гражданнарга /сәламәтлекләре начар булу сәбәпле уңайсыз шартларда калган/, гарипләргә, ятим балаларга, күзәтүчесез һәм тәрбиячесез калган балигъ булмаганнарга ярдәм күрсәтү;

балигъ булмаган хокук бозучылар өчен билгеләнгән махсус укыту-тәрбияләү учреждениеләрендә җәмгыяви эшләр алып бару;

психологик ярдәмнең һәм яраклашуның төрле хезмәтләрен оештыру;

ирегеннән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән һәм махсус укыту-тәрбияләү учреждениеләреннән кайткан яшь гражданнарга ирекле тормышка яраклашуда, шул исәптән аларны эшкә урнаштыруда һәм аларның көнкүрешен җайлауда ярдәм итү;

балаларны һәм яшьләрне үстерүдә ярдәм итү һәм шартлар тудыру буенча законнарда каралган башка вазыйфаларны үтәү.

2. Балалар һәм яшьләр өчен җәмгыяви хезмәтләр системасында җәмгыяви хезмәткәрләр сыйфатында эшләү өчен үзләренең шәхси сыйфатлары буенча билгеләнгән таләпләргә җавап бирә торган һәм тиешле белеме /белгечлеге/ һәм һөнәре булган яисә җәмгыяви өлкәдә эшләп махсус тәҗрибә туплау нәтиҗәсендә әлеге бурычларны үтәүгә сәләте булган, шулай ук билгеләнгән тәртиптә аттестация узган затларга рөхсәт ителә. Аттестация үзенчәлекләре республиканың Балалар һәм яшьләр мәнфәгатьләре буенча дәүләт комитеты тарафыннан билгеләнә.

<u>34 статья.</u> Компенсация фондлары, балалар һәм яшьләр өчен башка фондлар

I. Махсуслаштырылган компенсация фондлары, балалар һәм яшьләр өчен башка фондлар дәүләт органнары һәм башка органнар тарафыннан түбәндәге максатлар өчен төзелә:

яшь гражданнарга, яшь гаиләләргә ташламалы куллану кредитлары бирү өчен;

яшь гражданнарның шәхси һәм күмәк предприятиеләренә ташламалы кредитлар бирү;

финанс тәвәккәллеген иминләштерүче һәм яшь предприятиеләргә гарантияләр /җаваплылыкны үз өстенә алу/ бирүне тәэмин итү өчен;

яңалык кертүче программаларны финанслау өчен;

кредит учреждениеләренең алынып бетмәгән табышларын тулыландыру өчен;

башка чыгымнарны финанслау өчен;

2. Югарыда күрсәтелгән фондларның акчасын оештыру түбәндәгеләр исәбеннән гамәлгә ашырыла:

республика бюджетыннан;

җирле Советлар бюджетыннан;

дәүләт банкларыннан;

шартнамә нигезендә коммерция банкларыннан һәм башка банклардан;

компенсация, коммерция фондларыннан,максатчыл фондлардан һәм башка рәвешле дәүләт фондларыннан, җирле һәм иҗтимагый фондлардан.

3. Күрсәтелгән яшьләр фондларының акчасын оештырганда кертемнәр күләме һәм тәртибе Балалар һәм яшьләр мәнфәгатьләре буенча дәүләт комитеты, балалар һәм яшьләр мәнфәгатьләре буенча җирле органнар тәкъдиме нигезендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте, хакимиятнең һәм идарәнең җирле органнары тарафыннан закон нигезендә билгеләнә.

4. Югарыда күрсәтелгән фондларның акчаларын тоту гамәлгә куючы карары нигезендә балалар һәм яшьләр мәнфәгатьләре буенча фондларның яисә органнарның житәкчеләре вәкаләтендә була.

5. Балалар һәм яшьләрнең махсуслаштырылган фондлары арасында төзелгән килешү нигезендә төбәк, республика һәм республикаара фондлар төзелергә мөмкин.

6. Җәмгыяте хәйрия фондлары өчен каралган законнарда күрсәтелгән кагыйдәләр әлеге фондларга да кагыла.

## 7 бүлек

## Дәүләтнең яшьләр сәясәтен финанс ягыннан тәэмин итү

### 35 статья. Дәүләтнең һәм төбәкләрнең яшьләр сәясәтен финанслауның төп чыганаклары

I. Дәүләтнең һәм төбәкләрнең яшьләр сәясәтен финанслауның төп чыганаклары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

республика бюджеты;

халык депутатлары җирле Советларының бюджетлары.

Дәүләтнең һәм төбәкләрнең яшьләр сәясәте республикада шулай ук түбәндәгеләр хисабына да финанслана:

дәүләт банклары;

шартнамә рәвешендә коммерция банклары һәм башка банклар;

компенсация, коммерция фондлары, комплекслы һәм башка бюджет фондлары, бюджеттан тыш фондлар;

балалар, яшүсмерләр һәм яшьләр инициативаларының махсуслаштырылган фондлары;

предприятиеләрнең, оешмаларның, учреждениеләрнең һәм берләшмәләрнең үз акчалары;

балаларны һәм яшьләрне үстерүгә юнәлдерелгән максатчыл чит ил заемнары, кредитлары;

җәмгыяте хәйрия кертемнәре;

башка керемнәр.

2. Республика һәм җирле бюджетларның тиешле бүлекләрендә яшьләр сәясәте өлкәсендәге гамәлләрне финанслау өчен кирәкле ассигнованиеләр карала, аларның күләмнәре законнарда билгеләнә торган гарантияләнгән минимумнан ким булмаска тиеш.

3. Республикада яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән акча республика, шәһәрләр, районнар бюджетында аерым юл белән күрсәтелә.

4. Яшьләрнең хуҗалык берләшмәләре түли торган салымнар һәм салым булмаган түләүләр, предприятиедәге балалар һәм яшьләр оешмаларының хуҗалык эшчәнлегеннән һәм әлеге балалар һәм яшьләр оешмалары предприятиеләренең хуҗалык эшчәнлегеннән салымнар /әгәр алар салым түләүдән азат ителмәгән булсалар/ тулысынча республика бюджетына һәм җирле бюджетка җибәрелә һәм балаларның, яшьләрнең җәмгыяви мәсьәләләрен хәл итү өчен файдаланыла.

5. Республикада яшьләр сәясәте өлкәсендәге гамәлләрне финанслау тәртибе әлеге Закон һәм башка норматив актлар нигезендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә. Финанслау тәртибенә үзгәрешләр Татарстан Республикасы Югары Советының Яшьләр мәнфәгатьләре, физик тәрбия һәм спорт буенча даими комис-

сиясе күрсәтмәләрен исәпкә алып кертелә.

36 статья. Дәүләтнең һәм төбәкләрнең яшьләр сәясәтенең төп гамәлләрен финанслау

1. Дәүләтнең һәм төбәкләрнең яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән бюджет акчасы республиканың һәм җирле Советләрның җәмгыяви һәм икътисадый үсеш программаларында каралган ,республиканың һәм җирле төбәкнең балаларга һәм яшьләргә кагылышлы комплекслы һәм максатчыл программаларына, шулай ук балалар һәм яшьләр мәнфәгатьләре буенча органнарны һәм аларга буйсынган учреждениеләрне тоту өчен файдаланыла.

2. Республиканың һәм җирле төбәкнең комплекслы һәм максатчыл программалары, шул исәптән яңалык кертүче һәм күзаллау программалары түбәндәге чыгымнарны күз алдында тоталар;

дәүләтнең барлык баскычтагы яшьләр сәясәте өлкәсендәге әлеге Законда һәм башка норматив актларда каралган мәсьәләләрне хәл итү һәм шундагы бурычларны, максатларны гамәлгә ашыру өчен;

җирле һәм төбәк яшьләр сәясәте өлкәсендәге кичектергесез мәсьәләләрне хәл итү өчен аерым шәһәрләргә һәм районнарга бирелә торган максатчыл субсидияләр һәм дотацияләр өчен;

республика территориясендәге яшьләр оешмаларына бүленә торган субсидияләр һәм дотацияләр өчен;

яшь гражданнарны җәмгыяви яклау өчен;

милекне хосусыйлаштыру барышында яшь гражданнарның ихтыяҗларын яклау өчен;

халыкара балалар һәм яшьләр элемтәләрен гамәлгә ашыру өчен;

яшьләр сәясәте өлкәсендә яңалык кертү рәвешләрен, үзидарәнең яңа рәвешләрен тәэмин итү өчен;

республикада балалар һәм яшьләр мәнфәгатьләре буенча органнарның кадрлар составын әзерләүне һәм аларның осталыгын арттыруны яисә яңадан укытуны тәэмин итү өчен;

балалар һәм яшьләр мәнфәгатьләре буенча органнар карамагындагы объектларны төзү һәм тоту өчен;

яшьләр сәясәте өлкәсендә төрле гамәлләр һәм чыгышлар уздыру өчен;

әлеге Законда каралган башка мәсьәләләр өчен.

3. Яшь гражданнарны үстерү өчен бүленгән акча бюджетның башка статьялары буенча бүленми.

4. Яшьләр сәясәте өлкәсендә җәмгыяви, матди һәм гуманитар хезмәт күрсәтүче җәмәгать оешмаларының һәм дәүләткә карамаган башка оешмаларның устав максатлары нигезендә бүленгән акчаны бәрәкәтле тотуны һәм файдалануны балалар һәм яшьләр мәнфәгатьләре буенча органнар тикшереп тора.

<u>37 статья.</u> Яшьләр сәясәте гамәлләрен һәм субъектларын финанслау тәртибе турында

I. Яшьләр сәясәте гамәлләрен һәм субъектларын финанслауны кредитлар белән тәэмин итеп эш йөртүчеләр - Татарстан Республикасының Балалар һәм яшьләр мәнфәгатьләре буенча дәүләт комитеты һәм балалар һәм яшьләр мәнфәгатьләре буенча җирле органнар аша финанс органнары башкара.

2. Финанслау бюджетта расланган ассигнованиеләр чикләрендә һәм төп кредит бүлүчеләр тарафыннан финанс органнарына бирелә торган чыгымнар сметалары /керемнәр һәм чыгымнар сметалары/ нигезендә башкарыла.

3. Финанслау яшьләр сәясәте өлкәсендә расланган программалар нигезендә оешмаларның һәм учреждениеләрнең гадәти эшләвен тәэмин итәрлек вакытларда башкарыла.

4. Яшьләр сәясәте субъектлары гамәлләрен финанслау күләмнәрен киметү /арттыру/ законнарда билгеләнгән тәртиптә, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан кабул ителгән карарлар нигезендә тормышка ашырыла.

8 бүлек

Әлеге Законны гамәлгә ашыру гарантияләре

38 статья. Әлеге Законда беркетелгән хокукларның гарантияләре

1. Яшь гражданнарның, яшь гаиләләрнең, яшьләр оешмаларының әлеге Законда беркетелгән хокуклары һәм бурычлары, яшь гражданнарның эшчәнлеге гамәлдәге законнарда каралган нигезләмәләр буенча һәм тәртиптә чикләнгән очраклардан гайре, аларның үзләре тарафыннан турыдан-туры һәм тулы күләмдә тормышка ашырыла.

2. 2.1. Әгәр дә бу хокукларны үтәү аларның гамәлгә ашырылу тәртибен һәм процедурасын билгеләүне таләп итә икән, дәүләт хакимияте һәм идарә органнары әлеге мәсьәләләрне җайга салучы кирәкле норматив һәм башка хокукый актларны кабул итәргә тиеш.

2.2. Әлеге актларны кабул иткәнче яшь гражданнар, балалар һәм яшьләр оешмалары үзләренең хокукларын гамәлдәге законнарга каршы килми торган һәм үзләре мөстәкыйль сайлаган тәртиптә тормышка ашырырга хаклы.

2.3. Мондый очракларда хокукларны гамәлгә ашыруга ничек тә булса каршы килү законсыз дип санала.

2.4. Әгәр хокукларны гамәлгә ашыру һәм яклау дәүләт оешмаларының һәм урындагы затларының гамәлләр кылуы белән бәйле булса, мондый гамәлләрне кылу тәртибе /процедурасы/ законнарда беркетелмәгән булса, аның тәртибен бу оешмалар мөстәкыйль рәвештә үз вәкаләтләре чикләрендә билгеләләр, ә хокукларны яклаганда - гамәлдәге законнар нигезендә билгеләнә.

2.5. Алдан билгеләнгән тәртипнең /процедураның/ булмавы хокукларны гамәлгә ашырудан һәм яклаудан баш тарту өчен нигез була алмый.

<u>39 статья.</u> Әлеге Законның аның үсешендә кабул ителә торган актлар белән үзара мөнәсәбәте һәм әлеге Законны бозган өчен җаваплылык

I. Әлеге Закон тарафыннан яшь гражданнарга, яшьләр оешмаларына бирелгән хокукларны чикләүче шушы Законнан чыгарылган актлар, аларны кабул итү мизгеленнән тулысынча яисә өлешчә гамәлдән чыккан дип санала.

2. Хуҗалыктагы һәм башка бәхәсләрне хәл итүче судлар һәм органнар эшләрне тикшерү һәм бәхәсләрне хәл итү барышында шушы Законнан чыккан актларның әлеге Законның нигезләмәләренә туры килмәвен тапсалар, алар әлеге Законга таянып эш итәләр.

3. Дәүләт органнары һәм җирле органнар Законны гамәлгә ашыруга кагылышлы норматив һәм башка хокукый актлар кабул ит-

кэндә һәм аларны гамәлгә ашырганда әлеге Законның нигезләмәләрен үтәү өчен җаваплы булалар.

4. Әлеге Законга каршы килүче шушы Законнан чыккан актны гамәлгә ашыру, эш башкару яки башкармау нәтиҗәсендә яшь гражданнарга, яшьләр оешмаларына китерелгән зыян суд карарлары нигезендә бу закон актын кабул иткән, бу эшне башкарган яисә башкармаган дәүләт органы, җирле орган, предприятиеләр, оешмалар яки берләшмәләр карамагында булган акчалар исәбенә тулы күләмдә кайтарыла.

40 статья. Әлеге Законны үтәүне күзәтеп һәм тикшереп тору

I. Әлеге Законны төгәл һәм бертөрле итеп башкаруны күзәтеп тору Татарстан Республикасы Прокурорына һәм аңа буйсынган прокурорларга йөкләнә.

2. Әлеге Законны гамәлгә ашыруны халык депутатлары Советлары, дәүләтнең тиешле органнары һәм җирле органнар тикшереп тора.

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Шәймиев

Казан,
I993 елның I9 октябре
№ I983-XП